КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 6 октябрь г.Казань № 1255

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 939 нчы карары белән расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контроле турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 939 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 24 декабрь, 1276 нчы; 2022 ел, 22 июль, 713 нче; 2023 ел, 25 август, 1019 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контроле турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

7 пунктка түбәндәге эчтәлекле «д» пунктчасын өстәргә:

«д) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Йорт эчендәге һәм фатир эчендәге газ җиһазын кулланганда һәм карап тотканда куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча чаралар турында» 2013 елның 14 маендагы 410 номерлы карары белән расланган Йорт

эчендәге һәм фатир эчендәге газ җиһазын кулланганда һәм карап торганда куркынычсызлыкны тәэмин итү өлешендә газны куллану кагыйдәләренең 11 пунктындагы «а» пунктчасында һәм 12 пунктында каралган таләпләрне үтәү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин